# Фәйрүшин Габделәзәл Әхмадиша улы иҗаты

**Рәисә**

Яшьлек сукмагының мәшәкатен
Бергә үткәч кенә,
Аерылгангамы соң, Рәисә?
Үпкәләдеңме әллә, югыйсә?
Көн дә юлга чыксам.
Гел кире җил исә,
Каргадыңмы әллә яисә?

Син үстергән гөлнең ал чәчәген
Өзәргә кушкач та,
Өзмәгәнгәме соң, Рәисә?
Ачуландың мәллә югыйсә?
Көн дә эштә чакта
Гел кире җил исә.
Каргавыңмы әллә яисә?

Дистә еллар узып хәлләреңне
Бер тапкыр да
Белмәгәнгәме соң Рәисә?
Рәнҗедеңме әллә югыйсә?
Көн дә кичкә керсәм,
Гел кире җил исә
Каргадыңмы әллә яисә?

**Карауҗадан сәлам җибәрәм**

Бик сагындым сине авылым,
Әллә уйлагангамы?
Ак балыклар төсле
Ташу суларында
Чумып уйнагангамы?

Юксынам шул әле дә гомеремнең
Үткәнгәме синдә яртысы?
Һаман ай шикелле
Шомлы төннәреңне
Яктыртамы факел яктысы?

Истән чыкмый әле дә күлләреңнән
Якты күлең белән Пинәрәң.

Авылдашларыма
Якын дусларыма
Ераклардан сәлам җибәрәм.

Якын туганнарга
Сагындырганнарга
Карауҗадан сәлам җибәрәм.

**Мин риза**

Мин телимен синең белән
Чулман аша кичәргә.
Мин риза син кайтарган
Чишмә суын эчәргә.

Мин телимен синең белән
Ал таңнарны күтәргә.
Мин риза синең белән
Җир читенә китәргә.

Искән җилләр хыяллардан
Чынлап әйләнер микән?
Минем теләк хыяллардан
Чынга әйләнер микән?

**Аккан сулар кире кайтмый диләр**

Аккан сулар кире кайтмый, диләр.
Болытларда,
Кайта әле аның бөртеге.
Синең белән узган гомеремнең
Кайтса иде әле бер төне.

Искән җилләр кире кайтмый, диләр
Җир әйләнеп,
Кайта әле аның хәлсезе.
Мин дә сиңа кайткан була идем.
Булалмадым ярның әрсезе.

Яшь гомерләр ике килми, диләр
Кемнәргәдер,
Килә икән ул да яңадан да.
Миңа да ул килгән төсле булыр
Һичюгында булсаң җеназамда

**Татар кызы**

Стиляга кызлар кебек
Кашларыңны каралтмыйсың.
Серле күзең белән үзеңә
Кемне генә каратмыйсың.
Шул исәптән мине дә.

Кигән киемнәрең пөхтә,
Кер тидереп каралтмыйсың.
Ыспай сының белән үзеңә
Кемне генә каратмыйсың.
Шул исәптән мине дә.

Әдәпсезлекләр кыйланып
Язмышыңны каралтмыйсың.
Тыйнаклыгың белән үзеңә
Кемне генә каратмыйсың.
Шул исәптән мине дә.

Ефәк төсле чәчләреңне
Пыр туздырып таратмыйсың.
Уңганлыгың белән үзеңә
Кемне генә каратмыйсың.
Шул исәптән мине дә.

Кешедән кеше аралап
Нурлы йөзең каралтмыйсың.
Татлы телең белән үзеңә
Кемне генә каратмыйсың.
Шул исәптән мине дә.

**Шәледә**
/Алабуга-Казан юлындагы авыл/

Яшьлегемдә юл узганда
Ял иттем мин Шәледә.
Олыгайдым, шул вакытны
Искә алам әле дә.

Матур иде тирә-юне
Ул тигез урамнары.
Урамындагы моңнары.
Бер “Гүзәле” аннары.

Уңганлыгы белән шул кыз
Дан тоткандыр Шәледә.
Килешле иде үзенә
Ул бөркәнгән шәле дә.

Күзләре аның зәңгәр күл,
Кашлары –камышлары.
Булды микән ул “Гүзәлнең”
Бик якын танышлары.

Тагын бер туктармын әле
Ял итәргә Шәле дә.
Чыгып көт син мине, Гүзәл
Исән булсаң әле дә.

**Чәчләр чәчкә кайчан бәйләнер микән?**

Җир түгәрәк бер өзлексез
Шуңа әйләнә микән?
Күзең серле шуңа синңа
Күңелем бәйләнә микән?

Ай түгәрәк җир тирәли
Шуңа әйләнә микән?
Йөзең нурлы шуңа сиңа.
Күңелем бәйләнә микән?

Сине күрсәм белмим нигә,
Башым әйләнә икән?
Буең зифа шуңа сиңа
Күңелем бәйләнә микән?

Синең юлың минем яннан
Кайчан әйләнер икән?
Синең чәчең минем чәчкә
Кайчан бәйләнер микән?

**Ча,ча, ча**

Их, дусларым, җыр башлыймын
Исеме аның ча, ча.
Әйдә, сез дә кушылыгыз!
Җырлау күңелне ача,

Ча, ча, ча, ча, ча, ча.
Җырлау күңелне ача.

Мәҗлестә җырлау өчен
Иң кулай җыр ча, ча, ча
Стаканны кәгеп куеп,
Бераз булыйк кызмача,
Ча-ча-ча-, ча-ча-ча.
Бераз булыйк кызмача.

Бер җырласаң онытылмый
Әлеге җыр ча-ча-ча.
Мәҗлескә җаннар иңсен,
Җырлап җибәр, кодача!
Ча-ча-ча, ча-ча-ча.
Җырлап җибәр, кодача.

**Рәхмәтлегә рәхмәтле мин**

Кырык ел бик күп бала
Өйрәттем һәм тиргәдем.
Нервны күпме какшатып,
Җитәрлек күп тирләдем.

Шул чакны искә алгалап,
Рәхмәт әйтәм Дәүлигә.
Бәйрәм саен тәбрик итә
Яке кызы Мәүлидә.

Кемнәр генә өйрәнмәде:
Юныс, Гөлшат, Әсгап тә.
Ун ел үткәч, кичә керде
Коньяк тотып Әсгать тә.

Болын чәчәкләре кебек
Алар шундый тиз үсә.
Зур җыенда рәхмәт әйткән
Күрше кызы Дилюсә.

Инде күпләр онытылган,
Әмма алар беләләр.
Автобуска керү белән
Урыннарын бирәләр.

Дөнья булгач торгалыймын

Юл читендә, чатларда.
Үз шоферларым таныйлар
Әнә шундый чакларда.

Кайда гына яшәмиләр?!
Себер, Казан, Шөгердә
Рәхмәтлегә рәхмәт әйтәм,
Ошбу кыска шигырьдә.

**Убыр**

Без сабый чакта һәрбер урында,
Сөйлиләр иде убыр турында.

Аны күрделәр эткә охшатып,
Булмаган аны һичкайчан атып.

Я мәче булган карлы буранда,
Адәм куркыткан төнге урамда..

Ут булып төшкән юлчы алдына,
Кертми йөрткән ул аны авылына.

Әйләнә икән убыр кешегә,
Сәнәк аерсаң килеп төшүгә.

Сәнәк юклар аерса түшен,
Ул хәлсезләнә, син шуны төшен.

Ялвара убыр, куша тимәскә,
Һәм сорый аннан убыр димәскә.

Әмма ул була авыл кешесе,
Ә кайчакларда якын күршесе.

Бу сөйләгәннәр барсы – әкият
Сөйлим мин сезгә чып-чын хикәят.

Барчагыз белә – юк инде убыр,
Бел, хәзер убыр – кләүзник булыр.

Убыр шикелле йөрми ул үзе,
Нык яшергән аның чын йөзе.

Күп эшне йөртә хат аша гына,

Үзе күренә саташса гына.

Аның имзасы була, “ата-ана”,
“эшче”, “колхозчы” – дип тәмамлана.

Кләүзник булса, әгәр тирәндә,
Тамыр җибәртмә һаман тирәнгә.

Юлдагы ташкын күпме юл яра,
Кләүзник сала шундый ук яра.

Аер сәнәген: булсын саф кеше,
Илгә аның да кирәк саф эше.

/Кләүзник – яла ягучы/

**Ятка вәгъдә бирми тор!**

Телеграмм баганасы
Аралары йөз метр.
Иркәм чумсам Чулманыма,
Иркәм чумсам Чулманыма,
Ак пароход йөзми тор!

Электр баганасының
Буе бардыр ун метр.
Иркәм булса болыннарда,
Иркәмнең баш очларына
Кара болыт кунмый тор!

Тойма суы үзе тирән
Иңе бары өч метр.
Иркәм булса, бакчаларда
Иркәм йөргән бакчалардан
Сайрар кошым очмый тор.

Иркәм сине төштә күрдем
Ара калды бер метр
Яз кайтмасам, көз кайтырмын
Көз кайтмасам, бер кайтырмын
Ятка вәгъдә бирми тор!

**Кем ни өчен борчыла?**

Карау суы кичкәнем бар
Иделне кичсәң иде.
Шешәсеннән эчкәнем бар,
Мичкәдән эчсәң иде

Алдаучы:
Кырык алдар минем атым
“Алдым” димен алмасам.
Бик тынычлап йоклар идем
Тагын берне алдасам.

Карак:
Төн буе йөрдем урлауга
Бер нәрсә күрмәдем бит.
Үз казыгымны булса да
Суырып кермәдем бит.

Комсыз:
Эш хакын да артык алдым
Рәхмәтен ник әйтте соң?
Их, сорыйсым калган икән
Тагын бер биш-алты сум.

**Кыз җыры**

Сизәм мине күзәтәсең
Син бит минем карчыгам.
Чәчләремнән сыйпар булсаң
Гына каршыңа чыгам.

Сизәм мине күзәтәсең
Син бит минем карчыгам.
Ләззәтләнеп кочар булсаң
Гына каршыңа чыгам.

Сизәм мине күзәтәсең
Син бит минем карчыгам.
Иренемнән үбәр булсаң-
Гына каршыңа чыгам.

Сизәм мине күзәтәсең
Син бит минем карчыгам.
Имгәтеп калдырмас булсаң

Гына каршыңа чыгам.

Бик күптәннән күзәтәсең
Син бит минем карчыгам.
Гомерлек яр итсәң генә
Сиңа тормышка чыгам.

**Аңлат!**

Болыннарга алып килдең
Матурлыкны күрергә.
Чәчәкләрне җыйдык сиңа
Такыялар үрергә.

Бакчагызда син сыйладың
Бирдең җиләк-җимешең.
Арабыз бик якынайды
Тойдык йөрәк тибешен.

Аклы күлмәк бүләк иттең
Җәй көнендә кияргә.
Миннән калды сиңа шунда:
“Мәхәббәтем” дияргә.

Бергә йөреп күңелемә
Җылы хисләр сеңдердең.
Ә бераздан шул хисләрне.
Аңлат, нигә сүндердең?

**Ун сорауга бер җавап**

- Балдан да татлырак әйбер нәрсә? – Бел!
  Син белмәсәң әйтәм инде – тел!

- Әче тормадан әчерәк нәрсә? – Бел!
Син белмәсәң әйтәм инде – тел!

- Дарудан да шифалырак нәрсә? – Бел!
Син белмәсәң әйтәм инде – тел!

- Агудан да зәһәр әйбер нәрсә? – Бел!
Син белмәсәң мин әйтәм – тел!

- Әз генәдән сөендерә нәрсә? – Бел!
Син белмәсәң мин әйтәм – тел!

- Энә очыннан да очлы нәрсә? - Бел!
Син белмәсәң мин әйтәм – тел!

- Туганнарыңнан биздерә нәрсә? – Бел!
Син белмәсәң мин әйтәм – тел!

- Кешеләрне аралаштыра нәрсә? – Бел!
Син белмәсәң мин әйтәм – тел!
-
- Күршеләрне дуслаштыра нәрсә? – Бел!
Син белмәсәң мин әйтәм – тел!
-
- Үтмәс балтадан да тупас нәрсә? – Бел!
Син белмәсәң мин әйтәм – тел!

Күрәсең күп төшенчәне
Алыштыра тел.
Тик әйбәт якларын гына
Син куллана бел!

**Офыклардан ук таныймын**

Әле без йокыда чакта
Сездә ата алсу таң.
Төшләремдә күреп ятам
Син килгәнне офыктан.

Кушымта:
Офыклардан ук таныймын
Атлап килүләреңне.
Онытасым юк әдәп саклап,
Мактап көлүләреңне.

Тәңкәләр тезеп бизәдем
Мин алган йөгәнемне.
Офыклардан күзәтәмен
Ни эшләп йөргәнеңне.

Кушымта:
Офыклардан ук таныймын
Атлап килүләреңне.

Онытасым юк тыйнак кына,
Мактап көлүләреңне.

Парлап йөргән сукмаклардан
Суларга барасыңмы?
Искә алып, күрмәмме , дип
Офыкка багасыңмы?

Кушымта:
Офыклардан ук таныймын
Атлап килүләреңне.
Онытасым юк, гел шаяртып
Мактап көлүләреңне.

**Мартта**

Көн артыннан ай үтә,
Февраль да калды артта.
Һәр ел саен булып тора
Күп үзгәрешләр мартта.

Әйтерсең лә ак юрганга
Күктән кислота төшкән.
Карагызчы  басуларга,
Ничек үтәли тишкән.

Тишекләрдән борын төрткән
Үсемлекләр – тереләр.
Каргаларны каршылыйлар
Тал чыбыкта бөреләр.

Артыннан да җитеп булмый
Көннәр һаман озая.
Сузыла урман буенда
Сабырсыз умырзая.

Мартта инде килеп бетә
Кошларның эреләре.
Йоклап калмый – тереләләр
Күңелнең бөреләре.

**Аз сөтле сыер**
(мәсәл)

Печән ашагач, сыер суын эчә.
Ял итәргә уйламый ул көндәгечә.

План корды урамны урап керергә,
Яңалыкны һәм танышларын күрергә.

Менә күпмедер кеше капкадан үтә,
Ошбу сыер чыгып китәр җай көтә

Менә бәхет, капкадан үтә бала.
Ә артыннан капка шар ачык кала.

Шул чак сыер урамга таба шыла,
Дус түгел тәмле аш эзли аңлашыла.

Бара үзе тирә-янны күзәтә,
Капкасыз ишек алдына күз ата.

Керә, шунда күрә читтә бер ләгән,
Менә ризык бары тик ул теләгән.

Чупыр-чупыр эчә ул онлы суны,
Никтер хуҗа әзрәк салган шуны.

Туймаса да ошбу хуҗаны мактый,
Үз хуҗасын хурлап ташлады шактый.

- Өйдә миңа тәмлене гел бирмиләр,
Ә үзләре сөтең әз дип, тиргиләр.

Калыр иде бу йортта торып һаман,
Юк шул моның торагы, печән, салам.

Мораль: Торган җирен хурлый кайбер кешеләр,
Күрәм, алар нәкъ бу сыер ишеләр.

**Куплетлар**

Гармунчылар гармун уйный
Җырларга кушалар дыр.
Таң алдыннан кошлар сайрый,

Җырларга кушалар дыр.

Башыма да китермәдем
Язмыш болай итәсен.
Хәләл җефетемнән калып,
Гомер ялгыз үтәсен.

Көндез囲 эштә юанасың,
Читен кичен, иртәсен.
Башны ташка бәреп булмый,
Инде ни хәл итәсең.

Ходаем сиңа ялварам,
Авыртмасын бер төшем.
Күңелемне куандырсын,
Таңда күрәчәк төшем.

Йокым шундый тыныч булсын,
Көч бирсен беләгемә.
Сиңа  гел дә табынырмын
Ирешсәм теләгемә.

Чит җирләрдә шундый озак йөрдем,
Тузып бетте өйдән кигәнем.
Сабыр канатларым сынды инде,
Шундый сагындырды сөйгәнем.

Күзләреңне күрми калган идем,
Зәңгәр икән синең күз алмаң.
Әгәр сине таңда күрми калсам,
Кичкә кадәр күрми түзәлмам.

Мин килгәчтен яннарыңа,
Авыр сулап көрсенмә!
Ачык чыраеңны күрсәт
Инде анысын күпсенмә.

Ишегеңнең келәсен
Мин килгәндә эләсең.
Әллә шулай шаяртасың,
Әллә миннән көләсең?

Конфет юк шул кесәмдә.
Егет булып йөрсәм дә.
Оят инде шуңа /күрә/ сиңа

Кунак булып керсәм дә.

Син килгәчтен зәңгәр күктә,
Күзәтергә ай да юк.
Сагынуга түзә алмыйм,
Җырлап карыйм, файда юк.

Шундый озын чәчләреңне
Бер утырып тарасаң,
Риза инде киткән чакта,
Бер тутырып карасаң.

Киткән чакта җырладың да,
Исердем бит моңыннан.
“Ялгыз ничек түзәр бу?”-дип,
Уйладыңмы соңыннан.

Көн дә алсу таңда,
Өй түрендә талда,
Килеп кунган булыр бер чыпчык.
Авырсынма, иркәм, чыгып аны тыңла,
Миннән сәлам әйтер, белеп чык.

Безне таныштырган иде
Учактагы күмерләр.
Мәңге истән чыкмас инде,
Ул чактагы гомерләр.

Авызың тулы алтын теш,
Капланган үз тешләрең.
Кемнәр тирәсендә йөртә
Таңда күргән төшләрең.

Аклы күлмәкләрем булса,
Башканы кимәс идем.
Килер исәпләрең булса,
Башканы сөймәс идем.

Минем атым алмачуар,
Синең кашкадыр инде,
Мин булмагач яннарыңда
Хәзер башкадыр инде.

Дөньяларны гизәр идем
Ялгыз яшәп армасам.

Кичер мине!? Зинһар өчен
Яннарыңа бармасам.

Төрле сорт дип утыртсам да,
Әнис булды бер алмам.
Кичер, язын баралмадым,
Хәзер җәйсез баралмам.

Кабат-кабат барып карыйм
Йөрегән тирәләрне.
Онытa алмыйм ич һаман да,
Узган хатирәләрне.

Урамны өйләнер идем,
Булса кулда гармуным.
Җиһанга таралыр иде
Бар сагышым, бар моңым.

Исмәгез җилләр исмәгез,
Сөйгәнем ягыннан да.
Хатлар язсын, үзе килсен,
Өзелеп сагынганда.

Чәчең кара, буең зифа,
Әмма авызың кыек.
Аны төзәтеп булмый шул
Ясалма тешләр куеп.

Тәүге ярлар әйбәт була
Яратып сөяр өчен.
Алар белән кавышмыйлар
Сагынып сөйләр өчен.

Тәүге ярлар сиңа килми,
Өзелеп көткәндә дә.
Хәлеңне дә белми алар
Өзлегеп киткәндә дә.

Үскән чакта бик күп күрдем
Буранын да, давылын.
Читкә киткәч, сагындыра
Урамың да авылым.

**Күршеләрем.**

Балаларым янда түгел,
Еракта туганнарым.
Ярый таптым күршеләрнең
Үз итә торганнарын.

Йомыш төшсә, иң беренче,
Гел күршегә керәмен.
Йомышымны да үтимен,
Якты чырай күрәмен.

Иртә таңда теләшәбез
Хәерле көннәр генә.
Безнең татулыгыбызга
Сокланмас кемнәр генә.

Мәҗлес-туйлар булганда,
Һәрвакыт йөрешәбез.
Үпкәләшеп утырмыйбыз,
Җырлыйбыз, көлешәбез.

Нинди генә хәл булса да,
Беренче – күрше кирәк.
Минеке кебек күршеләр
Буладыр ул бик сирәк.

Борчу-хәсрәт дигәннәре
Буладыр кемнәрдә дә.
Аны да бергә җиңәрбез
Алдагы көннәрдә дә.

Моннан соң да “күрше” диеп
Бер-беребезгә дәшәрбез.
Калган гомеребезне дә
Шулай тату яшәрбез.

**Сине сагынам**

Олыгайдым инде, шуңа күрә
Ашыгырга эшем юк.
Оныта алмыйм сине, сине сагынам
Башка сагыныр кешем юк.

Нинди генә әйбәт булсалар да,

Сине алыштырыр күршем юк.
Онытa алмыйм сине, сине сагынам,
Башка сагыныр кешем юк.

Иртән торгач инде киңәшергә
Минем синдәй ишем юк.
Онытa алмыйм сине, сине сагынам,
Башка сагыныр кешем юк.

**Бер ялгызым шул мин хәзер**

Бер ялгызым шул мин хәзер
Сызылып таңнар атканда да,
Бер йотым суга тилмереп
Торалмыйча ятканда да.

Бер ялгызым шул мин хәзер
Гөлләр чәчәк атканда да,
“Кыйгак, кыйгак!” – дип киек казлар
Каңгылдашып кайтканда да.

Бер ялгызым шул мин хәзер
Сил җилләре искәндә дә,
Яшь чагыбызны сагынып
Син исемә төшкәндә дә.

Бер ялгызым шул мин хәзер
Ашымны ашаганда да.
Өметләнеп дәшә алмыйм
Ул сиңа охшаганда да.

Бер ялгызым шул мин хәзер
Иреннәрем кипкәндә дә,
Төркем-төркем саубуллашып
Киек казлар киткәндә дә.

Бер ялгызым шул мин хәзер,
Таңнан озын юл алсам да.
Юксынып эзләр кешем юк,
Шул юлымда югалсам да.

Бер ялгызым шул мин хәзер...

**Ямансу да, моңсу да**

Сине эзләп кырга чыксам,
Тургай гына басуда.
Ялгыз башка кайда да бер,
Ямансу да, моңсу да.

Сине эзләп күлгә төшсәм,
Үрдәкләр генә суда.
Ялгыз башка кайда да бер,
Ямансу да, моңсу да.

Сездән искән җилне тыңлыйм,
Ул да озын моң суза.
Ялгыз башка кайда да бер,
Ямансу да, моңсу да.

**Йолдызлар эзләп кенә!**

Өй түрендә миләш кенә,
Әз-әзләп өләш кенә!
Айлы кичтә күк йөзеннән
Йолдызлар эзләш кенә.

Бакчагызда шомырт кына,
Чык шунда шыпырт кына!
Ефәк төсле чәчләреңнән
Бер генә сыйпат кына!

Өй түрендәге бавыңда
Аклы кер генә киптер.
Чия төсле ирененңнән
Бары бер генә үптер!

**Калды ике эз генә**

Урманнарга кердек, юлларында
Калды ике эз генә.
Сайрар кошларны тыңладык
Бары икебез генә.

Күл буена төштек, ярларында
Калды ике эз генә.
Суга карап хыялландык
Бары икебез генә.

Болыннарга чыктык,үләннәрдә
Калды ике эз генә.
Сиңа, дип чәчәкләр җыйдык
Бары икебез генә.

Биек тауга мендек, итәгендә
Калды ике эз генә.
Тик кыясына менә алмадык
Бары икебез генә.

**Ризык йөртә бәндәне**

Урман эчендәге күлләр
Үз иркеннән кипмиләр.
Улларың да, туган авылым,
Үз иртеннән китмиләр.

Кушымта:
Читкә китәр улларыңны
Каһәрлисең әледәме?
Ризык кайда, бәндә шунда,
Ризык йөртә бәндәне.

Күлләреңнән киек казлар
Ризык беткәч китәләр.
Чит җирләрдә калган кызларың
Саргаеп гомер итәләр.

Кушымта:
Читкә киткән кызларыңны
Каһәрлисең әледәме?
Ризык кайда, бәндә шунда,
Ризык йөртә бәндәне.

Күлдән күлгә күчкән балык
Яраклашалмый бугай.
Рәхәт түгел читтә калган
Улларыңа да шулай.

Кушымта:
Читкә китәр улларыңны
Каһәрлисең әледәме?
Ризык кайда, бәндә шунда,

Ризык йөртә бәндәне.

Сиңа кайтып яшәр өчен
Өч кенә омтылмадым.
Синдә калды яшьлек чагым,
Һич кенә онытылмадым.

Сагынып гомер итәмен
Дусларымны, өйне дә.
Ризык кайда, мин дә шунда,
Ризык йөртә мине дә.

**Мансура**

Сахраларда җыр җырласам,
Җил очырта, Мансура!
Сагындым шул, ышанмасаң,
Искән җилләрдән сора!

Болыннарда чәчәкләрне
Сиңа җыям, Мансура!
Юксынам шул, ышанмасаң,
Сары чәчәктән сора.

Су буенда суга карыйм,
Күрмәмме дип, Мансура!
Зарыгып көтәм, ышанмасаң,
Агым сулардан сора!

Кичкә керсәм, күккә карыйм,
Күктән көтәм, Мансура!
Өмет өзмим, ышанмасаң,
Зөһрә йолдыздан сора!

**Мәдинә**

Ялгыз гына басып торам
Агым суның читендә.
Син булмаганга янымда
Ямансу да, читен дә.

Сине генә сөямен бит, Мәдинә!
Ишетмәмешкә салышып “Ә?” – димә.
Бакчадагы чәчәкләрне, гүзәлем,
Миннән узып башкаларга “Мә!” – димә!

Сөйгәнемне син тойсын дип,
Айга үрелим микән?
Әллә тирән күлгә батып,
Шунда сүрелим микән?

Сине генә сөямен бит, Мәдинә!
Ишетмәмешкә салышып “Ә?” димә.
Кулыңдагы чәчәкләрне, кадерлем,
Миннән узып башкаларга “Мә!” димә.

**Ник сорадым икән?**

Шундый салкын буранда
Йөргән чакта урамда,
Туңмыйсыңмы, иркәм, диеп
Ник сорамадым микән?
Әле тәкъдим итсәм
Җылы сулышымны.
Бик соңламадым микән?

Чәчәкле киң болында
Утыргач бер урында,
Чәчәкләр сөясеңме, дип
Ник сорамадым икән?
Әле тәкъдим итсәм
Җыйган чәчәкләрне,
Бик соңламадым микән?

Җәйнең айлы кичендә
Йөргән чаклар исемдә.
Серләшүчең бармы, диеп
Ник сорамадым икән?
Әле тәкъдим итсәм
Җылы хисләремне,
Бик соңламадым микән?

**Җәй көннәренә охшаган**.

Җәй көннәренә охшаган
Көзләр дә була икән.
Синең күзләргә охшаган
Күзләр дә була икән.

Йөзек кашына охшаган
Ташлар да була икән.
Синең кашларга охшаган
Кашлар да була икән.

Яран гөленә охшаган
Исләр дә була икән.
Синең хисеңә охшаган
Хисләләр була микән?

**Өметемне өзмим әле**

Синен белән киңәшмичә
Киттем шул ялгыш.
Күз күрмәс ерак җирләргә
Илтте шул язмыш.

Кушымта:
Әче язмыш илтсә дә еракка,
Салса да тозакка озакка,
Өметемне өзмим әле,
Бер күрешербез әле,
Бәлки аңлашырбыз да,
Бер килешербез әле.

Әче язмыш мине илткән
Синнән шундый еракка.
Ишетелми инде назлы
Сүзләрең дә колакка.

Кушымта

Сине ташлап китмәс өчен
Җитмәде акылларым.
Бер күрешергә тилмереп,
Сузам, җитми кулларым.

Әче язмыш илтсә дә еракка,
Салса да тозакка озакка,
Өметемне өзмим әле,
Бер күрешербез әле,
Бәлки аңлашырбыз әле,
Бәлки аңлашырбыз да,
Бер үбешербез әле.

**Җитмәгән “ни” син икән**

Ашыйм дисәм, ашым бар,
Эшлим дисәм, эшем бар.
Әмма миңа нидер җитми,
Шул борчу күңелдән китми.

Ял итәргә бакчам бар,
Тотыйм дисәм, акчам бар.
Әмма миңа нидер җитми,
Шул борчу күңелдән китми.

Чиккән кулъяулыгым бар,
Зарланмыйм, саулыгым бар.
Әмма, миңа нидер җитми,
Шул борчу күңелдән китми.

Сокланырга талым бар,
Куанырга малам бар.
Әмма миңа нидер җитми,
Шул борчу күңелдән китми.

Борчылудан җир әйләндем –
Туган илем киң икән.
Тик соңыннан гына белдем,
Җитмигән “ни” – син икән.

**Оныттыңмы кайтыр юлларыңны?**

Онытмаска булдың, язмыш сине
Диңгез аръягына ташласа да,
Иңнәреңне авыр таш басса да.
Ник кайтмыйсың һаман?
Оныттыңмы әллә кайтыр юлларыңны,
Оныттыңмы әллә йөргән юлларыңны,
Яшьлек елларыңны?

Алыштырмас булдың мине башкаларга,
Үзең өчен алсу таңнар туып торганда да.
Ник кайтмыйсың һаман?
Оныттыңмы әллә кайтыр юлларыңны?
Оныттыңмы әллә мин барын?

**Мин берәүгә кар аттым**

-Ни булса, шул булыр, - диеп
Мин берәүгә кар аттым.
Ул миңа шундый карады!
Күз карашын яраттым.

Йөрәгенә барып тигән,
Күрәсең, мин төз аттым.
Матур сүзләр сөйли-сөйли
Гаебемне төзәттем.

Шулай итеп күңелемдәге
Борчуларны тараттым.
Аның куенына кереп
Ятуларын яраттым.

-Ни булса да, шул булыр, - дип
Ярый әле кар аттым
Үземнеке итеп аны
Гомерем буе яраттым.

**Кайтам әле сиңа**

Тәүге ярым сиңа кайтыр өчен,
Өч кенә омтылмадым.
“Онытты ул!” – димә , рәнҗи күрмә!
Һич кенә онытылмадың.

Агым суда әгәр агып китсәм,
Тотып алырсың микән?
Сиңа атап әгәр җыр җырласам,
Отып калырсың микән?

Хатлар язам сиңа сагынганга,
Дәфтәрем тутырып.
Хатым барса әгәр, иренмичә
Укырсыңмы утырып?

Җитәр микән белмим, җитмәс микән
Талым читән үрергә?
Кайтам әле сиңа , һичъюгында
Сине читтән күрергә.

**Рәхмәт әти-әнигә!**

Җир әйләнеп чыкмасам да,
Күп йөрдем тирә-юньдә,
Алай да мин бәхетсез дип,
Зарланыйммы? Ә нигә?
Аяклар бүләк иткәннәр
Рәхмәт әти-әнигә!

Чит илләрне күрмәсәм дә.
Күрдем якты дөньяны ,
Алай да мин бәхетсез дип,
Зарланыйммы? Ә нигә?
Күзләрне бүләк иткәннәр
Рәхмәт әти-әнигә!

Миллионер ук булмасам да.
Ризык табам үземә,
Алай да мин бәхетсез дип,
Зарланыйммы? Ә нигә?
Көч-куәт бүләк иткәннәр
Рәхмәт әти-әнигә!

Тәхеттә утырмасам да,
Хезмәт итәр урын бар.
Алай да мин бәхетсез дип,
Зарланыйммы? Ә нигә?
Зиһен дә бүләк иткәннәр
Рәхмәт әти-әнигә!

Сиксән яшькә җитмәсәм дә,
Алтмышны уздым инде.
Алай да мин бәхетсез дип
Зарланыйммы? Ә нигә?
Рухымны бүләк иткәннәр
Рәхмәт әти-әнигә!

**Оҗмах кайда дисезме?**

Әйтсәм әйтим сер итеп,
Бераз хыялга китеп.
Оҗмах бала чагында

Әниләр кочагында.

Ә инде бераз үскәч,
Борын асларың кипкәч;
Ягъни, үсмер чагында
Табигать кочагында.

Эзли күрмә хәзердән
Ул оҗмахны кабердән.
Оҗмах ул кыз чагында
Яшь егет кочагында.

Капкан итнең кисәген
Өзәлмәсәң тешләп тә;
Инде үзең беләсең,
Оҗмах җылы түшәктә.

Җан тәслим кылгач Алла:
“Гөнаһың бармы?” – дияр.
“Без гөнаһсыз, иншалла.
Оҗмах кабердә тияр.

**“Көнләшүеңме?”-ди**
**Көнләшмим, юк, юк, юк...**

“Соңлап кайттың” – диеп
Искәртер хәлем юк.
“Көнләшүеңме? – ди. Көнләшмим
юк, юк, юк.
Тик сәгатьләр буе дәшмим.

“Башка вакытлы кайт!” –
Дип кисәтер хәл юк.
“Көнләшүеңме?” – ди, көнләшмим
юк, юк, юк.
Тик көн буе эндәшмим.

“Кем өчен бизәндең?” –
Дип сорар хәлем юк.
Көнләшүеңме? – ди, көнләшмим
юк, юк, юк.
Тик атна буе эндәшмим.

Көнләшәмме белмим

Ул чак бер дә көлмим.
Хатынымнан бер дә күз алмыйм.
Ни дисә дә дияр, инде нишлим?
Шуннан артык дәшми түзәлмыйм.

**Зөләйха (бәет)**

Кичке тугыз тулып килә иде,
Син дөньядан ычкынуың.
Яныңда ук түгел идем.
Белмим ни дип кычкырдың?

Әйтмәдең дә кайда, кайчан
Саулыгыңны калдырдың?
Ярый әле истәлеккә
Сүрәтеңне калдырдың.

Сүрәтең куен кесәмдә
Карыйм да куям шунда.
Булгансың икән син минем
Аем да, кояшым да.

Әй, әй Зөләйхам!
Аклы күлмәк алдырдың.
Картлыгымда терәк өчен
Өч баһадир калдырдың.

Булгансың икән син минем
Индийский чәем дә.
Җанга рәхәт, тәнгә җылы
Сандугачла җәем дә.

Әй, әй Зөләйхам!
Аклы күлмәк калдырдың.
Үзеңне хәтерләтергә
Гүзәл бер кыз калдырдың.

Булгансың икән син минем
Җиләкләрем бакчамда.
Күз алдымнан һич китмисең
Күзне йомып баксам да.

Әй, әй Зөләйха!
Аклы күлмәк алдырдың.
Син бит минем күңелемдә

Бары тик эз калдырдың.

Юксынып сарайга чыксам,
Сарыклар сырып ала.
“Хуҗа анабыз кая?- дип
Алар да сорап ала.

Яфраклар бирәм аларга,
Ашамый сабын алар.
Күрәсең мин генә түгел,
Алар да сагыналар.

Күңелләрем буп-буш калды
Син генә биләгәнсең.
Минем бөтен тормышымны
Син генә бизәгәнсең.

Өй түрендә җир калдырдым
Бер сирень өчен генә.
Яшәгәнмен икән үзем
Гел синең өчен генә.

Изгелекләрең күп булды
Инде оныта алмамын.
Син яртысын, мин яртысын
Ашый идек алманың.

Печән чабармын дисәм дә,
Чаптым инде күрән дә.
Һуштан язам күл өстендә
Ялгыз аккош күргәндә.

Ялгыз аккош йөзә күлдә.
Артында кала күбек.
Картаймыш көнемдә калдым
Шул ялгыз аккош кебек.

Миңа дигән ризыкларны
Беркем дә алмагандыр.
Картлыгында минем хәлдә
Беркем дә калмагындыр.

Күңелемнән елыйм, ә күзләрдән
Чыкмый инде сыгылып яшем дә.
Ялгыз каен кебек калдым синнән

Илле тугыз яшемдә.

Ниләр генә үстермәдек,
Кайсылары уңмады.
Алай да бит безнең яшәү
Зарланырлык булмады.

Шомырт чәчәк аткач, сине
Күрәм күк тереләтә.
Ул синең ак шәл ябынган
Чагыңны хәтерләтә.

Чәчкәләрен койгач, сине
Күрәм күк тереләтә.
Ул синең яшел күлмәктән
Торганны хәтерләтә.

Шомыртлары пешкәч, сине
Күрәк күк тереләтә.
Ул синең каш астындагы
Күзләрне хәтерләтә.

Күзем ачып ни күрсәм дә
Гел сине хәтерләтә.
Инде яныңа бармыйча
Күрәлмам тереләтә.

Ташладың дә киттең,
Ялгыз иттең.
Хәзер юк бит синдәй ишләр дә.
Төшләремә кереп булса да, әйт!
Инде хәзер миңа нишләргә?

***<u>Бу шигырьләрне сайтка куярга Ф.Бәшәрова әзерләде. 2021 ел, апрель</u>***



Фотода басып торучыларның уңнан беренчесе - Фәйрүшин Габделәзәл